**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мэсгут авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мэсгут авылы № 62 3 март 2015 ел.

Мәсгүт авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мәсгүт авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Мәсгүт авылы башкарма комитетының 05 май 2014 елда чыккан 12 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Мәсгүт авыл җирлеге Советының 08 май 2014 елда чыккан номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Мәсгүт авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Мәсгүт авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 апрель 2015 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Мәсгүт авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - Мәсгүт ,Яхшы-Бай авылындагы зиаратларны төзекләндерү
   - ӘЙЕ ЮК
3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Р.Х.Аскаров